
Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы
Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе



# Көмеш кыңгырау

№2
октябрь,
2014 ел

**“Балалык – кеше тормышының иң мөһим чоры, ул - киләчәк тормышка әзерлек кенә түгел, бәлки чын, якты, үзенә генә хас кабатланмас тормыш. Бүгенге нәнинең нинди кеше булып үсүе сабыйның балачагы ничек үтүенә, балалык елларында аны кем тәрбияләвенә, әйләнә-тирә мохиттән аның аңына һәм йөрәгенә нәрсә сеңүенә бәйле”, - дигән В.А. Сухомлинский.**

## Бәйрәмегез белән, кадерле укытучылар!



6 октябрь көнне мәктәбебездә Укытучылар көне билгеләп үтелде. Бәйрәмгә ветеран укытучыларыбыз да килгән иде.

Укучылар укытучыларны бәйрәм белән тәбрик итеп, чәчәк бәйләмнәре бүләк иттеләр, концерт номерлары күрсәттеләр.

***

**Укытучым,
шундый назлап
Карадың күзләремә.
Сүнмәслек зур дәртләр
салдың
Кечкенә йөрәгемә.
Син җитәкләп алып
менден мине
Тауларның биегенә.
Алып киттең далаларга,
Диңгезләр киңлегенә.
Яктыртты һәрбер
көнемне,
Кояш нурлары белән.
Син яктырттың
күңелемне,
Белем нурлары белән.**



***

**Хөрмәтле
укытучыларыбыз!
Сезнең хезмәт
җирдә иң хөрмәтле,
Сезнең хезмәт
җирдә нур чәчә.
Сез бик кирәк
барлык кешеләргә,
Йөз яшәгез җирдә,
мең яшә!**
***

### Кызыклы фактлар:

- ✓ Россиядә беренче официаль булган дәүләт мәктәбе Петр 1 нче заманында барлыкка килгән. Ул 12-17 яшьлек малайлар өчен эшләгән.
- ✓ Чехиядә “1” - иң яхшы билге, “5” - иң начары.
- ✓ Иң күп укучылы мәктәп Индиядә булган. Анда 28000 укучы укыган.
- ✓ Иң озын дәрес 2003 елда Австралиядә уза. Ул 54 сәгать дәвам итә. Биология профессоры лекциясен шул кадәр сәгать укый.







## 1 октябрь — Өлкәннәр көне

Мәктәбебез тимурчылары, «1 октябрь — Өлкәннәр көне» уңаеннан, Казаклар, Кече һәм Олы Кибәхуҗа авылында яшәүче күп кенә әби-бабайларда булып, аларны бәйрәм белән тәбрик иттеләр, шигырьләр сөйләделәр, үзләре ясаган бүләкләрен тапшырдылар, йорт эшләрендә үз ярдәмнәрен тәкъдим иттеләр. Өлкәннәребез аларга зур рәхмәтләр әйтеп калды.









### Бу номерда:


| | |
|---|---|
| Укытучылар көне | 1 бит |
| Өлкәннәр декадасы | 1 бит |
| Агач утырту | 2 бит |
| Олимпиадалар | 3 бит |
| Мәктәп сайты яңалыклары | 4 бит |
| Туган ягымда алтын көз | 5 бит |
| Туган көннәрегез котлы булсын | 6 бит |

# Без утырткан агачлар шаулап үсәр



Агачларның нинди генә төрләре юк иде



Агач утыртуда берәү дә читтә калмады



Агач утыртырга һәркем әзер

10 октябрь көнне республикакүләм оештырылган агач утырту көне үтте. Бу игелекле эштә безнең мәктәбебездә укучы барлык укучылар һәм укытучылар да бик теләп, актив катнаштылар. Барысы 36 төп агач һәм куак утыртылды. Тиздән без утыркан агачлар шаулап үсәр һәм тирә-якка ямь биреп торырлар. Без барыбыз да тирә - якның яшеллеге һәм экологик чиста һава яклы.



Агач утырту эшенә Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбе укучылары да кушылды. Алар да мәктәп тирәсенә агачлар, куаклар утырттылыр.

## Агачлар да авырый

Яз башлануга Рәмиләнең әтисе көн дә бакчада була. Ул агач төпләрен йомшарта, корыган ботакларны кисә. Рәмилә әтисе янында йөрергә ярата.

- Әти, агач төбен нигә казыйсың?

— Агач төбен йомшартам, кызым,— ди әтисе.

— Нигә йомшартасың аны?

— дип сорый Рәмилә.

— Йомшартмаган агачка су сипкәч, аның төбе катып кала. Су агач тамырларына кадәр үтә алмый. Тамырлар һава да сулый алмыйлар.

— Агачлар да сулыймы?

— Сулый, кызым. Алар өчен дә һава кирәк.

Беркөнне кемдер бакча ишеген ачык калдырган. Шуны гына көткән кәҗә бакчага кереп тә китә. Рәмиләнең әтисе, тиз генә чыбык алып, кәҗәне куып чыгара.

Рәмилә:

— Әти, нигә кәҗәне куасың?

— дип сорый.

Әтисе Рәмиләне бакчага алып керә, кәҗә кимерә башлаган агачны күрсәтә.

— Кимерсә ни була?

— Агачларыбыз авырый, яфраклары саргая, үзе корып кала. Аннан соң ул алма бирми башлый.

— Агач та авырыймы?


— Авырый, кызым, хәтта корып, үлеп тә китә.

— Бу алмагач та корыймы инде, әти? — дип сорый ул, еламсырап.

— Бәлки, корымас,— ди әтисе.— Без хәзер бу агачны дарулап, бәйләп куярбыз. Шуннан соң Рәмилә авыру агач янына көн дә килеп йөри башлый. Ул әлеге агачның бөтерелә, яшеллеген югалта башлаган яфраклары яңадан яшәрә башлавын күреп куана. Ә беркөнне ул, шатлыгыннан сикерә-сикерә, бакчадан әнисе янына йөгереп керә.

— Әнием, агач терелгән, яфраклары көлеп тора,— ди ул.

*Зәкәрия Әхмәров*







# Фән олимпиадаларының мәктәп туры

22 сентябрьдән 28 октябрьгә кадәр мәктәпләрдә Бөтенроссия һәм республика фән олимпиадаларының мәктәп туры узды. Мәктәп турына биремнәр район мәгариф бүлегеннән җибәрелде. Шул биремнәр нигезендә егермедән артык предметтан фән олимпиадаларының мәктәп туры үткәрелде. Олимпидаларда 4 нче сыйныфтан 9 нчы сыйныфка кадәрге укучылар катнашты. Фәннәр буенча укучыларның белемнәре тикшерелде. Һәр фән буенча эшләрне бәяләү критерийлары килде. Шул критерийлар буенча укучы, җыярга мөмкин булган максималь баллның яртысыннан артыграгын җыйган ягъни 50% тан артык дөрес җавап биргән очракта гына, олимпиаданың муниципаль турына катнашу хокукы ала. Бу хокукка безнең мәктәптән 14 укучы лаек булды: 4 сыйныфтан — Гараев Г., 5 сыйныфтан — Ахметзянова А., Шәяхмәтова С., 6 сыйныфтан — Аскарова А., Рахматуллина Э., 7 сыйныфтан — Закиров Ф., Саидов В., Саидова М., Серапионов А., 8 сыйныфтан — Гильмутдинова Л., Ибраһимов Р., 9 сыйныфтан — Аскаров Д., Даутова Д., Сафиуллина И. Бу укучылар белән олимпиадага әзерлекнең расписаниесе төзелде. Шул расписание нигезендә укучылар олимпиадаларга әзерләнәләр. Муниципаль тур 17 ноябрьдән башланып, 24 декабрьгә кадәр барачак. Олимпиадаларның муниципаль турында укучыларга зур уңышлар телибез.

***Түбәндәге таблицада муниципаль турда катнашучы укучылар исемлеге күрсәтелгән:***

## Заявка на участие в муниципальном этапе всероссийских и республиканских олимпиад.

***Учебный год:*** ***2014-2015***
***Название школы:*** ***Малокибякозинская ООШ***

| №№ п/п | Предметы | Ф.И. участников по предметам и классам | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 7 класс | 8 класс | 9 класс | 5класс | 6 класс | 4класс |
| 1 | История | Саидова М. | Гильмутдинова Л. | Даутова Д. | | | |
| 2 | Математика | Саидова М. | Ибрагимов Р. | Сафиуллина И. | Ахметзянова А.<br>Шаяхметова С. | Рахматуллина Э. | Гараев Г. |
| 3 | Литература | Закиров Ф. | Гильмутдинова Л. | Сафиуллина И. | | | |
| 4 | Биология | нет | Гильмутдинова Л. | нет | | Аскарова А. | |
| 5 | Физика | | Гильмутдинова Л. | | | | |
| 6 | Английский язык | Саидов А. | | | Ахметзянова А. | | |
| 7 | Химия | | Гильмутдинова Л. | | | | |
| 8 | География | Серапионов А. | нет | нет | | Рахматуллина Э. | |
| 9 | ОБЖ | | | Аскаров Д. | | | |
| 10 | Обществознание | Саидова М. | Гильмутдинова Л. | Даутова Д. | | | |
| 11 | Физическая культура | нет | нет | Аскаров Д. | | | |
| 12 | Русский язык | Серапионов А. | Гильмутдинова Л. | Сафиуллина И. | | | Гараев Г. |
| 13 | Татарский язык | Закиров Ф. | Гильмутдинова Л. | Сафиуллина И. | | | |
| 14 | Татарская литература | Закиров Ф. | Гильмутдинова Л. | Даутова Д. | | | |

# Мәктәп сайты яңалыкларыннан...



**Авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре көненә багышланган ярминкәдә** 11.10.2014

Районыбыз үзәге Теләчедә авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәре көненә багышланган ярминкә гөрләп үтте. Ярминкәдә мәктәп коллективы да үзе җитештергән продукция, балаларның кул эшләре белән катнашты.



**Кәрәзле телефон ни сөйли?** 15.10.2014

Мәктәбебезнең башлангыч сыйныфлар укытучысы Газизова Р.Х. "Кәрәзле телефон ни сөйли?" исемле балалар иртәсе үткәрде. Иртәдә балалар телефоннарның килеп чыгу тарихы белән таныштылар. Әңгәмә барышында телефоннарның файдалы һәм зыянлы яклары аталды.



**География укытучылары семинары.** 24.10.2014

Бүген мәктәбебездә география укытучыларының район семинары булып үтте.Семинарның темасы: "Яңа федераль дәүләт стандартларына күчү шартларында география укытуда яңа алымнар". Катнашучылар 6 сыйныфта "Географик координаталар" темасына ачык дәрес карадылар. Дәресне мәктәбебезнең беренче категорияле география укытучысы Ф.Г.Әскарова үткәрде.



**Бөтенроссия конкурсы җиңүчесе.** 28.10.2014

Мәктәбебезнең югары категорияле математика укытучысы Әхмәтҗанова Н.Н. "Иң яхшы авторлык программасы" Бөтенроссия конкурсында катнашты. Укытучының конкурска тәкъдим ителгән 9 сыйныфлар өчен "Математик статистика һәм ихтималлылык теориясе" темасына электив курс программасы II урынны яулады. Конкурсны оештыручылар программаны югары бәяләде, Диплом белән бүләкләде. Әхмәтҗанова Найлә Нуретдиновнаны мәртәбәле конкурста җиңүе белән котлыйбыз.



**Инглиз теленнән тестлаштыру.** 29.10.2014

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 21 октябрендә чыккан 6040/14 номерлы "Татарстан Республикасы муниципаль оешмаларында 4нче сыйныф укучыларына инглиз теленнән тестлаштыру үткәрү турында"гы приказы нигезендә бүген үзебезнең Келче Кибәхуҗа төп һәм филиал - М.Мостафин исемендәге Олы Кибәхуҗа башлангыч мәктәбенең 4нче сыйныф укучылары инглиз теленнән диагностик тестлаштыру үтте.Тестлаштыру инглиз теленнән укучыларның белем дәрәҗәсен ачыклау максатыннан үткәрелде.



**Интернет челтәре куркынычсызлыгы.** 29.10.2014

Информатика укытучысы Галимҗанова Г.Ә. "Интернет челтәре куркынычсызлыгы" темасына ачык дәрес үткәрде. Дәрестә 2-9 сыйныфларда укучы барлык балалар, укытучылар катнашты. Укытучы Интернет челтәрендә булучы куркыныч сайтлар, вируслар, вируслы программалар белән таныштырды, бу куркынычлардан саклану чараларын аңлатты. Дәрес барышында карточкалар белән төркемләп эшләү оештырылды, укучылар анкета сорауларына җаваплар бирделәр, презентация, интернет сылтама аша видеоролик күрсәтелде.Соңыннан нәтиҗә ясалып, куркынычсызлык кагыйдәләре чыгарылды.

# «Уңыш бәйрәме” күңелле үтте

Һәр елны октябрь аенда мәктәпләрдә “Уңыш бәйрәме” үткәрелә. Быел бу бәйрәм безнең мәктәптә 30 октябрь көнне узды. Анда 1 сыйныфтан 5 сыйныфка кадәр булган укучылар катнашты. Бәйрәмгә барлык укучылар тырышып әзерләнделәр. Көзге муллык белән тулган өстәлләр, көзгә багышланган рәсемнәр күргәзмәсе залны бизәп торды.

Бәйрәмне мәктәп директоры Найлә Нуретдиновна ачып җибәрде. Ул укучыларның җәйге чорда башкарган эшләренә нәтиҗә ясады. Мәктәп яны участогында мул





уңыш үстерелүен, ул яшелчә, җиләк-җимешләрнең укучыларга туклану өчен тотылачагын җиткерде. Укучыларны күңелле ял итәргә чакырды.

Балалар матур итеп җырладылар, биеделәр. Төрле уеннарда үзләренең белемнәрен дә күрсәттеләр. Рус халык әкияте “Шалкан” ны сәхнәләштереп күрсәттеләр. Бәйрәм ахырында әниләре, әбиләре пешереп биргән тәмле ризыклар белән чәй эчтеләр. Бәйрәм бик күңелле үтте.

## ******* “Көзге бал” бәйрәме *******

## Туган ягымда алтын көз

Җиргә төшә сары, ал
яфраклар
Көз җиткәнен алар белдерә.
Алтын көзең, синең, туган
ягым
Күңелемә якын, бер генә.
***
Басуларың инде бушап
калган,
Икмәкләре кергән амбарга.

Алтын көзем, ямансулый
алмыйм,
Юксына да алмыйм син
барда.
***
Һәркайда да муллык һәм
сөенеч,
Һәрбер җирдә көзге
шатлыклар.
Кара көз дип сиңа беркем
әйтмәс

Кочагында муллык,
байлыклар.
***
Хуш киләсең әйдә, алтын
көзем,
Көтеп алдык кыш, яз, җәй
аша.
Безнең язмыш, килер
язмышларга,
Шундый көзләр аша
тоташа.













“Көзге бал” бәйрәменнән кайбер мизгелләр...

# Туган көннәрегез котлы булсын!

**Хөрмәтле укытучыларыбыз Әхмәтҗанова Найлә Нуретдиновна, Хуҗина Нәкыя Юнысовна, Газизова Рушания Хатиповна! Сезне туган көнегез белән тәбрик итәбез.**

Гомереӊ хәзинәсенә
Өстәлде тагын бер ел,
Моӊайма еллар үтә дип,
Елмай син - бәхетле бул!
Котлы булсын бәйрәмеӊ,
Тыныч булсын күӊелеӊ,
Шатлык-сөенечләр белән
Тулы булсын гомереӊ!
Гамьле еллар, ямьле көннәр
Телибез чын йөрәктән!
Һич кичекми чынга ашсын
Безнеӊ күркәм теләкләр!




**************************

******************




**************************

******************

**Кадерле укучыларыбыз Мөхәммәдиева Сиринә, Белозерова Диләфрүз, Шәнгәрәев Рушан! Сезне туган көннәрегез белән тәбрик итеп, иӊ изге теләкләребезне телибез.**

Бу көн шулай күӊелледер
Син туганга,
Бу дөнья шулай яктыдыр
Син булганга.
Бөтен җиһан шатлангандыр
Син туганга.
Тирә-якта һәрчак бәйрәм
Син булганда.
Бүгенгедәй сөйкемле бул!
Бүгенгедәй бәхетле бул:
Жәй гөлләре үскәндә дә,
Яз яфраклар ярганда да,
Көз җилләре искәндә дә,
Жиргә карлар яуганда да!

Кече Кибәхуҗа төп мәктәбе

422080, ТР, Теләче районы, Кече Кибәхуҗа авылы, Кече урамы, 10 нчы йорт

Телефон: 8(843)60 56 2 40
Эл. почта: mkibiakozi40@mail.ru

Редколлегия әгъзалары: *IX сыйныф укучылары*. Баш мөхәррир: *Г.Ә.Галимҗанова*